КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 23 гыйнвар г.Казань № 30

«2018 – 2025 елларга Татарстан Республикасында хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру һәм эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» өстенлекле төбәк программасын эшләү һәм тормышка ашыру буенча идарә итүче комитет төзү турында

Россия Федерациясе Президенты каршындагы Стратегик үсеш һәм өстенлекле проектлар буенча совет президиумы утырышының 2017 ел, 30 август, 9 нчы беркетмәсе белән расланган «Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру һәм эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» өстенлекле программасы кысаларында «2018 – 2025 елларга Татарстан Республикасында хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру һәм эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» өстенлекле төбәк программасын эшләү һәм тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «2018 – 2025 елларга Татарстан Республикасында хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру һәм эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» өстенлекле төбәк программасын эшләү һәм тормышка ашыру буенча идарә итүче комитет төзергә.

2. Бу карарга теркәлгән «2018 – 2025 елларга Татарстан Республикасында хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру һәм эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» өстенлекле төбәк программасын эшләү һәм тормышка ашыру буенча идарә итүче комитет турындагы нигезләмәне расларга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 23 гыйнвар, 30 нчы
карары белән расланды

«2018 – 2025 елларга Татарстан Республикасында
хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру һәм эш белән тәэмин итүгә
булышлык күрсәтү» өстенлекле төбәк программасын эшләү һәм
тормышка ашыру буенча идарә итүче комитет турында
НИГЕЗЛӘМӘ

1. Гомуми нигезләмәләр.

1.1. «2018 – 2025 елларга Татарстан Республикасында хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру һәм эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» өстенлекле төбәк программасын эшләү һәм тормышка ашыру буенча идарә итүче комитет (алга таба – Идарә итүче комитет) «2018 – 2025 елларга Татарстан Республикасында хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру һәм эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» өстенлекле төбәк программасын (алга таба – төбәк программасы) эшләүне, раслауны һәм тормышка ашыруны гамәлгә ашыручы ведомствоара орган булып тора.

1.2. Идарә итүче комитет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук бу Нигезләмәгә таянып эш итә.

2. Идарә итүче комитетның бурычлары һәм вәкаләтләре.

2.1. Идарә итүче комитетның төп бурычлары:

төбәк программасын эшләүгә һәм тормышка ашыруга бәйле карарлар кабул итү;

Идарә итүче комитетның эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итү өчен «2017 – 2025 елларга Татарстан Республикасында хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру һәм эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» өстенлекле төбәк программасының проект төркемен (алга таба – Проект төркеме) төзү;

Проект төркемендә катнашучылар, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең җаваплы башкарма органнары, үсеш институтлары һәм төбәк программасында катнашкан башка кызыксынучы якларның үзара хезмәттәшлек итүен оештыру;

төбәк программасын тормышка ашыру барышын бәяләү;

төбәк программасын тормышка ашыру турындагы докладларны һәм хисапларны, өстенлекле программаны тормышка ашыру мәсьәләләре буенча тәкъдимнәрне Россия Федерациясенең Икътисадый үсеш министрлыгына һәм башка кызыксынучы оешмаларга кертү.

2.2. Идарә итүче комитет түбәндәгеләргә вәкаләтле:

төбәк программасын эшләргә, расларга һәм тормышка ашырырга, шулай ук төбәк программасына үзгәрешләр кертү турында Россия Федерациясенең Икътисадый үсеш министрлыгына һәм башка кызыксынучы оешмаларга тәкъдимнәр җибәрергә;

төбәк программасы чараларының җыелма планын эшләргә, расларга һәм аңа үзгәрешләр кертергә, шулай ук төбәк программасының тикшерү нокталарын һәм этапларын үтү турында карарлар кабул итәргә;

төбәк программасының һәр чарасы буенча һәм тулаем финанслау күләмен исәпләү буенча тәкъдимнәр карарга, хупларга һәм Россия Федерациясенең Икътисадый үсеш министрлыгына кертергә;

Проект төркеменнән һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан төбәк программасын тормышка ашыру мәсьәләләре буенча материаллар һәм мәгълүмат соратып алырга;

Проект төркеме турындагы нигезләмәне расларга, аның составын (төркем әгъзалары белән килешеп) төзергә;

Проект төркеме тарафыннан кертелгән төбәк программасын тормышка ашыру турындагы хисапларны хупларга;

Проект төркеме әгъзалары эшчәнлеге максатларын һәм күрсәткечләрен билгеләргә, аларның эшчәнлеге файдалылыгын һәм нәтиҗәлелеген бәяләргә һәм аларны премия бирүгә тәкъдим итәргә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы белән «Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү һәм эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» өстенлекле программасын тормышка ашыруда катнашу мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы турында» 2017 ел, 21 июль, 513 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы вәкаләтле башкарма хакимият органының ведомство боерыгы белән түбәндәгеләрне раслауны яраштырырга:

хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру чараларын тормышка ашыручы һәм ташламалы шартларда җитештерүчәнлекне арттыру һәм аның буенча эшләнгән программасы максатлары өчен хезмәткәрләрне яңадан укыту программаларын эшләүне финанслауга дәгъва итүче төбәк программасында катнашучылар – пилот предприятиеләре исемлеген;

төбәк программасында катнашучылар – пилот предприятиеләре хезмәткәрләрен даими эшкә алучы һәм аларның эш хакларын өлешчә каплауга дәгъва итүче предприятиеләр исемлеген;

төбәк программасын тормышка ашыруда катнашучы, әмма җитештерүчәнлекне арттыру һәм хезмәткәрләрне яңадан укыту программаларын эшләүне финанслауга дәгъва итмәүче башка предприятиеләр исемлеген (предприятиеләр-менторлар, үз көчләре белән төбәк программасын эшләүче предприятиеләр һ.б.);

кирәк булганда, җитештерүчәнлекне арттыру буенча эшләнгән программалар яки төбәк программасының башка шартларын үтәмәгән предприятиеләрне төбәк программасында катнашучылар исемлегеннән төшереп калдыру өлешендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү һәм эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү»

өстенлекле программасын тормышка ашыруда катнашу мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы турында» 2017 ел, 21 июль, 513 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы вәкаләтле башкарма хакимият органының ведомство боерыгына үзгәрешләр кертүне яраштырырга.

3. Идарә итүче комитетның эш тәртибе.

3.1. Идарә итүче комитетның утырышлары аның җитәкчесе карары буенча, әмма айга кимендә бер тапкыр үткәрелә. Идарә итүче комитет әгъзалары чираттан тыш утырыш үткәрүне тәкъдим итәргә һәм утырышның көн тәртибенә тәкъдимнәр кертергә хокуклы.

3.2. Идарә итүче комитет җитәкчесе утырышларда рәислек итә, утырышларның көн тәртибен һәм аны үткәрү көнен раслый, эшне планлаштыра һәм Идарә итүче комитет карарларын тормышка ашыруны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра.

3.3. Идарә итүче комитет карарлары утырышта катнашучы әгъзаларның күпчелек тавышы белән ябык тавыш биреп кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

3.4. Идарә итүче комитетның карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм аңа утырыш үткәрелгән көннән өч эш көне эчендә Идарә итүче комитет рәисенең яки аның урынбасарының имзасы куела.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 23 гыйнвар, 30 нчы
карары белән расланды

«2018 – 2025 елларга Татарстан Республикасында
хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру һәм эш белән тәэмин итүгә
булышлык күрсәтү» өстенлекле төбәк программасын эшләү һәм
тормышка ашыру буенча идарә итүче комитет
составы

| | |
|---|---|
| Кәримов Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасының сәнәгать һәм сәүдә министры, Идарә итүче комитет җитәкчесе |
| Хөсәенов Алмаз Шәүкәт улы | Татарстан Республикасының сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары, Идарә итүче комитет җитәкчесе урынбасары |
| Әхмәров Марат Равил улы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының анализ бүлеге башлыгы, Идарә итүче комитет сәркатибе |
| Мартынов Евгений Васильевич | «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Энергия саклаучы технологияләр үзәге» дәүләт автоном учреждениесе директоры |
| Пелевин Олег Владимирович | Татарстан Республикасының икътисад министры урынбасары |
| Таҗетдинова Клара Алексеевна | Татарстан Республикасының хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары. |